# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге  Тархан торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**11 ноябрь 2025 ел** **№ 2**

Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге Тархан торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда 1төркем инвалидларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан тыш, Илбәк  авыл җирлеге  Тархан торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1 500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 750 (җиде йөз илле) сумга киметеп,  үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- **торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Заречная урамындагы 24нче йорттан алып - 34нче йортка; Лесная урамындагы 1А йортыннан алып – 7нче йортка кадәр юлга вак таш сатып алу, төяү, ташу, тарату);
- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту).

3. Әлеге карарны,  кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Тархан авылы, Лесная урамы, 2 йорт;  Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендынларында урнаштырырга һәм  Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru)  урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тархан авыл җирлеге башлыгы Р.К.Галимҗанова